РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАРЫ

**2020 елның 28 сентябре** **386 №**

**Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) вазыйфаи окладларын арттыру турында**

Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 октябреннән Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) айлык вазыйфаи окладлар күләмен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 апрелендәге "Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында"гы 164 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә арттырырга.

2. Әлки муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш

хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, вазифа окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аларны түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

а) Әлки муниципаль районы учреждениеләре өчен:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (башка җирле үзидарә органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 24 411 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 22 145 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчә җитәкчесе (баш хисапчы) | | 22 145 |
| Бүлек начальнигы | 18231 | 18231 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 15759 | 15759 |
| Хисапчы | 14420 | 14420 |

б) Әлки муниципаль районы авыл җирлекләре өчен:

| Вазифа | Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары халык саны белән | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 16 171 сум | 17 510 сум |
| Хисапчы | - | 14 935 сум |

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Әлки муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов